Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы карары

04.09.2017ел. № 60

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге » муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен раслау турында, «Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.3 өлешен, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре» 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указының 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен расларга, муниципаль берәмлектә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы булып торалар.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңасала авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.
3. Әлеге карар түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк ур., 1;
-ТР, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клуб урамы, 14 шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән.

Кама Тамагы муниципаль районының
Яңасала авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы Яңасала авыл җирлеге Советы Рәисе
муниципаль район башлыгы И. Х. Шиһабеев